| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 апрель 2019 ел** **№ 49/3**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 48/3 номерлы карарының 2.3 пунктына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Салым кодексының 32 бүлеге, РФ бюджет Кодексының 64 статьясы , Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 48/3 номерлы карарының 2.3 пунктына (советның 2015 елның 27 апрелендәге 58/2 номерлы, 2015 елның 14 декабрендәге 2/1 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 4/2 номерлы, 2018 елның 24 августындагы 35/1 номерлы, 2018 елның 26 октябрендәге 41/2 номерлы, 2018 елның 18 декабрендәге 45/2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәреш кертергә :

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турындагы гаризаны үз теләге белән тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

2. Әлеге карарны Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Чүпрәле муниципаль районы
Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы _____________ Албутов Олег Борис улы